**Җиңү язы**

1. Сиксәненче тапкыр җиргә
Килде быел җиңү язы.
“Җиңү” дигән сүзгә сыйган
Әнкәемнең бөтен назы.

Кушымта: Җиңү язы, җиңү язы –
Бабайлардан безгә бүләк.
Геройларга рәхмәт әйтеп
Тибә һәрчак безнең йөрәк.

2. Сиксәненче тапкыр язда
Горур атлый мәйдан буйлап,
Ура әйтеп, байрак тотып
Тигез сафлы хәрби парад.

Кушымта шул ук.

3. Һәр яз саен кабатлана
Бабаемның әйткән сүзе:
Кара болыт капламасын,
Аяз булсын илем күге!

Кушымта шул ук.